МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.01.2019 г.Казань № 31

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 07 февралендә 5426 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган

гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.07.2015 № 475, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 351, 27.11.2017 № 835, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 883 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.01.2019 ел. № 31нче боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 20 июлендәге 585 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә һәлак булган, нурланыш авыруы һәм Чернобыль һәлакәтенә бәйле рәвештә барлыкка килгән башка төрле авырулар нәтиҗәсендә вафат булган гражданнарны, шулай ук Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге инвалидлар исәбенә керүче вафат булган гражданнарны җирләүгә гаилә әгъзаларына яки җирләү оештыруны үз өстенә алган затларга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган
Үзгәрешләр

1 бүлекнең 1.5 пунктындагы сигезенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекнең 2.5 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 3 пунктчасында «РФ Хөкүмәтенең 1274 номерлы карары белән расланган 33 номерлы форма буенча» сүзләрен «үлемне теркәгәндә гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан бирелә торган, билгеләнгән формалы» сүзләренә алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Хөкүмәтенең 1274 номерлы карары» сүзләрен төшереп калдырырга.